ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## "Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 20 мартында
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында" 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш); 2008, № 1, № 12 (VI өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 2 пунктында "һәм вәкиллекләренә дә" сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 7 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"2. Республика башкарма хакимияте органнарының территориаль органнары урнаша торган урын республика башкарма хакимиятенең тиешле органнары тарафыннан билгеләнә.";

3) 9 статьяга түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:
"$4^1$. Татарстан Республикасы Президенты хокукый актлары кул куелган көненнән алып 14 көн эчендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәреләләр.";

4) 28 статьяга түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пункт өстәргә:
"$6^1$. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый актлары кабул ителгән көненнән алып 14 көн эчендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәреләләр.";

5) 35 статьяның 1 пунктында "вәкиллекләрен," сүзен төшереп калдырырга;

6) 39 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

7) 40 статьяның 3 пунктындагы тугызынчы абзацында ", вәкиллекләре һәм аларның урындагы затлары" сүзләрен "һәм күрсәтелгән органнарның вазыйфаи затлары" сүзләренә алмаштырырга;

8) 42 статьяның 2 пунктында "һәм вәкиллекләренең" сүзләрен төшереп калдырырга;

9) 43 статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

"6. Республика башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актлары Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары бердәм банкына кертелгән көннән алып 14 көн эчендә әлеге банкны булдыруга һәм алып баруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәреләләр.";

10) 45 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"үз вәкаләтләре кысаларында расасына, милләтенә, теленә, дингә мөнәсәбәтенә һәм башка хәлләргә бәйсез рәвештә кеше һәм гражданның хокуклары, ирекләре һәм законлы мәнфәгатьләре тигезлегенең дәүләт гарантияләрен тәэмин итү; социаль төркеме, расасы, милләте, теле яки дине билгеләренә карап хокукларын чикләүне һәм дискриминацияләүне булдырмау; Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының этномәдәни күптөрлелеген, аларның телләрен һәм мәдәниятен саклап калу һәм үстерү; милли азчылыкның хокукларын яклау; мигрантларны социаль һәм мәдәни адаптацияләү; милләтара (этносара) конфликтларны профилактикалау, милләтара һәм конфессияара килешүне тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыра.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 11 апреле
№ 22-ТРЗ